ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.03.2019 ел Баулы шәһәре №67

Административ комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләү өчен салынган административ штрафлар буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану һәм исәптән чыгару тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясы, «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендә кабул ителгән 229-ФЗ номерлы Федераль закон (2018 елның 27 декабре редакциясендә), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393нче номерлы «Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 1. Административ комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләү өчен салынган административ штрафлар буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану һәм исәптән чыгару тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 15 мартында кабул ителгән
67нче карары белән расланган

Административ комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләү өчен салынган административ штрафлар буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану һәм исәптән чыгару тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләү өчен салынган административ штрафлар буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану һәм исәптән чыгару тәртибе (алга таба - тәртип) түләүләр буенча бурычларны Баулы муниципаль районы бюджетына (алга таба - җирле бюджет) түләтүгә өметсез дип тану очракларын, түләүләр буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану турында карарлар кабул итү өчен нигезләр булуын раслаучы документлар исемлеген һәм активларны кертү һәм исәптән чыгару буенча комиссия (алга таба – Комиссия) гамәлләре тәртибен билгели.

1.2. Әлеге тәртип салымнар һәм җыемнар турында законнарда, житештерүдәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү турында Россия Федерациясе законнарында, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм таможня эше турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән түләүләргә кагылмый.

1.3. Әлеге Тәртиптә җирле бюджетка түләүләр буенча бурычлар дигәндә административ комиссия тарафыннан салынган һәм вакытында түләнмәгән һәм җирле бюджетка күчерелергә тиешле административ штрафлар күздә тотыла. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану инвентарьлаштыру үткәрү нәтиҗәсе буенча еллык хисап төзү алдыннан башкарыла.

1.4. Җирле бюджетка бурычларны түләтү ометсез дип тану инициаторы булып җирле бюджет керемнәренең баш администраторы (алга таба – керемнәр администраторы) тора, аңа бюджеттагы түләүләрне исәпләү, исәпкә алу һәм исәпләүнең дөреслеген, тулылыгын һәм вакытында башкарылуын, пеня һәм аның буенча штрафларны исәпләү, исәпкә алу һәм контрольдә тоту вәкаләтләре йөкләнгән.

1.5. Керемнәр администраторы бурычлар булуны ачыклый һәм Комиссия тикшерүенә җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү өметсез дип

тану турындагы мәсьәләне чыгара.

1.6. Керемнәрнең администраторы җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул ителгән көннән соң биш эш көне эчендә бухгалтерлык исәбе турында Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә баланс исәпеннән бурычлар суммасын төшереп калдыруны гамәлгә ашыра. Бурычны бетерү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47 статьясындагы 5нче пункты нигезендә башкарыла.

1.7. Керемнәр администраторы салым булмаган керемнәр төрләре буенча әлеге Тәртипкә 1нче кушымта нигезендә исәптән чыгарылган бурычлар реестрын алып бара.

## II. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану очраклары

2.1. Түбәндәге очракларда бурыч түләтү өметсез дип таныла һәм гамәлдән чыгарылырга тиеш:

а) административ штраф түләүче физик затның вафаты яки аны, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, үлгән дип белдерү;

б) бурычлының мөлкәте җитәрлек булмау сәбәпле, «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендә кабул ителгән 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә административ штраф түләүче индивидуаль эшкуарны банкрот дип тану;

в) административ штраф түләүче оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яисә) күрсәтелгән оешманың гамәлгә куючыларының (катнашучылары) түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле, әлеге оешманы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә бетерү;

г) суд тарафыннан акт кабул ителеп, аның нигезендә җирле бюджет керемнәре администраторы, аны түләттерү срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалтса;

д) әгәр җирле бюджетка түләүләр буенча бурычлар барлыкка килгәннән соң биш елдан артык вакыт үткән булса, түбәндәге очракларда суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма производство тәмамлану һәм «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендә кабул ителгән 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46нчы статьясындагы 1нче өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча, башкарма документны гариза бирүчегә кайтару турында карар чыгару:

бурыч күләме бөлгенлеккә төшү турындагы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләр күләменнән артмый;

суд банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтарса яки банкротлык турындагы эшне, суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле, туктатса.

2.2. Тәртипнең 2.1 пунктында каралган очраклардан тыш, билгеләнгән вакытка түләнмәгән административ штрафлар, тәнәфес, туктату яки озайту өчен нигезләр булмаганда, административ җәза билгеләү турында Россия Федерациясе кодексының билгеләнгән вакыты чыккан очракта, түләтүгә өметсез дип таныла.

### III. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар кабул итү һәм аларны исәптән чыгару өчен нигез барлыгын раслаучы документлар исемлеге

Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен нигезләрнең булуын раслаучы документлар булып торалар:

а) инвентарьлаштыру нәтиҗәләре турында акт (Россия Финанс министрлыгының «Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан кулланыла торган беренчел исәп документлары һәм бухгалтерлык исәбе регистрлары формаларын раслау турында» 2015 елның 30 мартындагы 52н номерлы боерыгы һәм аларны куллану буенча методик күрсәтмәләр» белән расланган ф. 0504835) (алга таба - Россия Финанс министрлыгының 2015 елның 30 мартындагы 52н номерлы боерыгы);

б) кергән акча буенча исәп-хисап елъязмасы (Россия Финанс министрлыгының 2015 елның 30 мартындагы 52н номерлы боерыгы белән расланган ф.0504091);

в) әлеге тәртипкә 2нче кушымтадагы форма буенча, җирле бюджетка түләүләрне түләү буенча исәпкә алына торган керемнәр администраторы хисабыннан өземтә;

г) җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында керемнәр администраторыннан белешмә;

д) җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар:

физик затның – җирле бюджетка түләү түләүченең үлемен яки аны вафат дип игълан итүне раслаучы документ;

Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан – җирле бюджетка түләүләр түләүче шәхси эшмәкәрне банкрот дип тану нәтиҗәсендә эшчәнлеген туктатуы, юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан бюджетка түләүләр түләүче оешманың бетерелүе белән бәйле эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ;

керемнәр администраторы, түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва вакыты) тәмамлануга бәйле рәвештә, җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны

түләттерү мөмкинлеген югалтуын раслаучы, шул исәптән җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерү турында судка бирелгән вакытның югалган вакытын кире кайтарудан баш тарту турында суд билгеләмәсен дә үз эченә алган суд акты;

«Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендә кабул ителгән 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма документны гариза бирүчегә кире кайтарганда башкарма җитештерүне тәмамлау турында суд приставы-башкаручының карары.

## IV. Активларны кертү һәм исәптән чыгару буенча комиссия турында нигезләмә һәм аның җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану турындагы карар чыгару һәм бурычны исәптән чыгару буенча эшчәнлеге тәртибе

4.1. Комиссия составы даими нигездә керемнәр администраторы тарафыннан раслана.

4.2. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссия эшчәнлеге белән рәис урынбасары җитәкчелек итә.

4.3. Комиссия утырышлары кирәк булганда үткәрелә.

4.4. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы санала. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез очракта Комиссия рәисе карар хәлиткеч тавыштан файдалана.

4.5. Комиссия утырышы беркетмәсенә комиссия рәисе һәм утырышта катнашкан барлык әгъзалар кул куя.

4.6. Комиссия 10 эш көне дәвамында керемнәр администраторы тәкъдим иткән документлар исемлеген карый һәм җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану һәм аны исәптән чыгару турында карар проектын әзерли.

4.7. Җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карар түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә (әлеге Тәртипкә 3нче кушымта):

а) оешманың тулы исеме (физик зат фамилиясе, исеме, атасының исеме);

б) салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт-теркәлү номеры, оешманың налог түләүче итеп исәпкә кую коды (салым түләүче физик затның идентификация номеры);

в) бурыч барлыкка китергән штраф турында мәгълүмат;

г) җирле бюджетка түләүләр буенча бурычлар исәпкә алынган Россия Федерациясе бюджетларының керемнәрен классификацияләү коды, аның

исеме;

д) жирле бюджетка түләүләр буенча бурыч суммасы;

е) җирле бюджетка административ штраф түләү буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану турында карар кабул итү датасы;

ж) комиссия әгъзаларының имзалары.

4.8. Комиссия тарафыннан җирле бюджетка административ штраф түләү буенча бурычларны түләтү өметсез дип тану һәм аны исәптән чыгару турындагы акт керемнәр администраторы җитәкчесе тарафыннан раслана.

---

Приложение 1
к Порядку принятия решений о признании
и списании безнадежной к взысканию
задолженности по уплате административных
штрафов, наложенных административной
комиссией в бюджет Бавлинского муници-
пального района Республики Татарстан

РЕЕСТР
списанной задолженности по платежам в бюджет
муниципального образования ______________________________по видам неналоговых доходов
за ________ год

______________________________________
(администратор доходов)

(руб.)

| № п/п | Основание признания задолженности безнадежной | Наименование организации (ИНН/КПП), Ф.И.О. физического лица (ИНН при наличии) | Вид платежа | Срок возникновения задолженности по уплате платежа | Сумма списанной задолженности, всего | в том числе: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Основной долг | Пени | Штрафы |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| ИТОГО | | | | | | | | |

Руководитель

М.П. ____________________ ________________________
(подпись)

(Ф.И.О.)

Приложение 2
к Порядку принятия решений о признании
и списании безнадежной к взысканию
задолженности по уплате административных
штрафов, наложенных административной
комиссией в бюджет Бавлинского муници-
пального района Республики Татарстан

ВЫПИСКА

из отчетности ___________________________________________
(администратор доходов)
об учитываемых суммах задолженности по уплате платежей
в бюджет муниципального образования _____________________________

_______________________________________________________
(наименование организации (ИНН/КПП),
Ф.И.О. физического лица (ИНН при наличии)
по состоянию на _______________года

(руб.)

| № п/п | Вид платежа | Срок возникновения задолженности по уплате платежа | Всего задолженность по уплате платежа | в том числе: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Основной долг | Пени | Штрафы |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| ИТОГО | | | | | | |

Руководитель ____________________ ________________________
М.П. (подпись) (Ф.И.О.)

Приложение 3

к Порядку принятия решений о признании
и списании безнадежной к взысканию
задолженности по уплате административных
штрафов, наложенных административной
комиссией в бюджет Бавлинского муници-
пального района Республики Татарстан

АКТ
о признании безнадежной к взысканию задолженности
по платежам в бюджет и ее списании

от «____» ____________ 20__ г. № _________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(полное наименование организации, фамилия, имя, отчество физического лица)

___________________________________________________________________________

(ИНН, ОГРН, КПП)

Сведения о платеже, по которому возникла задолженность

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(КДБ и его полное наименование)

Сумма задолженности __________ рублей ____ копеек.

На основании

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(указываются конкретные документы с указанием реквизитов)

Председатель комиссии:

____________________ _______________ ____________________________
(должность) (подпись) (Ф.И.О.)

Члены комиссии:

____________________ _______________ ____________________________
(должность) (подпись) (Ф.И.О.)

____________________ _______________ ____________________________
(должность) (подпись) (Ф.И.О.)